**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4162**
**10.06.2025**

Яр Чаллы шәһәренең «Заман» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмә, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе хакында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Заман» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Заман» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2020 елның 26 маендагы 2438 номерлы Карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка  йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 10 июнендәге
4162 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Заман» яшьләр үзәге»
муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан
күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәя |
|---|---|---|---|
| I. Балаларның, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең мәшгульлеген оештыру буенча хезмәтләр | | | |
| 1 | Бокс, самбо (кеше) | 1 дәрес | 500,00 |
| 2 | Вокал | 1 дәрес | 500,00 |
| 3 | Хореография | 1 дәрес | 500,00 |
| 4 | Кызыксынулар буенча клуб | 1 дәрес | 200,00 |
| 5 | Фитнес | 1 дәрес | 500,00 |
| 6 | Психологик-педагогик тренинг | 1 дәрес | 400,00 |
| 7 | Һөнәри юнәлеш буенча консультация (индивидуаль) | 1 дәрес | 500,00 |
| 8 | Һөнәри юнәлеш буенча консультация (төркем) | 1 дәрес | 300,00 |
| II. Чаралар үткәрү буенча хезмәтләр | | | |
| 1 | Бәйрәм программасы (кеше) | 1 хезмәт | 350,00 |
| 2 | Балалар уен программасы, дискотека (кеше) | 1 хезмәт | 350,00 |
| 3 | Иҗат буенча мастер класс (кеше) | 1 хезмәт | 300,00 |
| 4 | Тематик квест (кеше) | 1 хезмәт | 250,00 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева